Әхлак, тәрбия

# Җәмгыятебез алдындагы иң мөһим бурыч - яшь буынны тәрбияләү

**Мәктәп балаларына җәйге каникуллар вакытында тәрбия бирү, аларның вакытын файдалы үткәрү мәсьәләләре күпләрне электән борчып килделәр.**

**Аларны бары тик бер юл белән — Ислам диненә, шәригать кануннарына нигезләнгән тәрбия бирү белән генә хәл итеп булачагы соңгы елларда аеруча ачыкланды.**

**Ләкин дә гаиләдә, мәктәптә Исламга тиешле хөрмәт булмаган, аңардан язган җәмгыятьтә яшәүче балаларга дини тәрбия бирү - ул авыр хәл. Үткән 2010-2011 еллардагы җәй көннәрендә бу мәсьәләне тормышка ашыру өчен беренче адымнар ясалды.**

**Әлбәттә, беренче ике елда авырлыклар да, кимчелекләр дә булды. Инде менә 2012 елның беренче яртысында мөселман балалары өчен җәйге лагерь оештыру буенча төрле киңәшмәләр, җыелышлар булып узды. Әлбәттә, ахырда бу тырышуларның уңай нәтиҗәләре дә күренде.**

**Самара өлкәсе Диния нәзарәтенең җәмәгатьчелек һәм яшьләр белән эш итү бүлеге җитәкчесе Рифкать улы Радик ГАЗИЗОВ бу хакта түбәндәгеләрне сөйләде:**

— Без мөселман балалары өчен җәйге лагерь оештыруның төрле юлларын эзләп карадык. Аларның иң кирәклесен табу өчен төрле кыенлыклар аша үттек, җитешсезлекләрне дә җиңә алдык.

Быелгы киңәшүләрдә, сөйләшүләрдә без күп нәрсәне нечкәлекләре белән уртага салып сөйләштек. Нәтиҗәдә, файдалы һәм матур фикерләр тупланды. Күмәкләшеп уйланулар нәтиҗәсендә оптималь планнар корылды. Безнең төп максат - татар-башкорт балаларында Ислам диненә, гореф-гадәтләребезгә, телебезгә, милләтебезгә, чынбарлык тарихыбызга һәм мәдәниятебезгә карата хөрмәт хисләре уяту иде.

Аларны әхлак, намус төшенчәләрен белергә, начарны яхшыдан аерырга һәм сабырлыкка, түземлеккә өйрәтеп, матур сыйфатларга карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре уятырга тырыштык.

Шуңа күрә дә дөрес туклануга, хәләлне хәрәмнән аерырга өйрәтүгә һәм Ислам дине таләпләре буенча яшәүнең әһәмиятен аңлатуга без күп көч куйдык.

Балаларга Ислам дине гыйлемен аңлату өчен дин белгечләрен, ә туган телебез, тарихыбыз, милли мәдәниятебез турындагы мәгълүматларны балалар аңына җиткерү өчен «Яктылык» мәктәбеннән югары белемле, тәҗрибәле педагогларны да бу эшкә чакырып китердек.

Балалар үзләренең сәләтләрен тулысынча күрсәтә алсыннар өчен төрле бәйгеләр, конкурслар оештырылды. Табигать кочагында төрле уеннар уйнау, елгада су керү дә аларга зур файда китерде.

Мөһим фактор - үзара аралашу, дуслашу, төрле милләт балаларының тату яшәргә өйрәнүләре - бу да бит тәрбия чарасы.

Уеннар арасында, аштан соңгы ял вакытында без аларга, көчләмичә, вәгазьләр, кызыклы хәлләр, үрнәк булырлык вакыйгалар турында даими рәвештә сөйләп тордык. Гомумән, балаларны азрак тыеп, аларга күбрәк ирек бирергә тырыштык. Әлбәттә, дискотекаларга йөрү тыелды. Ләкин дә укучылар моңа бер дә күңелсезләнмәде.

Биредә балалар йортында тәрбияләнүчеләргә дә ял итү мөмкинлеге бирелгән иде. Татар балаларының әтиәниләре аларга күчтәнәчкә күп итеп төрле ризыклар алып киләләр. Ятим



Рәхимә Хәерова үз балалары белән

балалар ымсынып карамасын өчен, без аларга да өлеш чыгарырга кирәклеген аңлатып: «Сезнең әти-әниләрегез бар, ә алар ятим, әти-әни мәхәббәтеннән мәхрүм калган балалар», - дип төшендердек. Бу миһербанлык һәм юмартлык тәрбияләүнең табигый бер ысулы булды.

Балаларны намаз укырга да мәҗбүр итмәдек. Теләүчеләр үзләре безнең белән укыдылар. Без алар белән бергәләп Кинель-Черкассыдагы мәчеткә җомга намазына да йөрдек.

Башка милләт балалары белән аралашып ял итсәләр дә, татарларның мөселманча киенүләренә кырын карау, мыскыллау очраклары булмады. Киресенчә, безнең укучыларның тәртиплелегенә лагерь администрациясе хезмәткәрләре дә, төрле милләт балалары да сокланып карадылар. Төрле ярышларда, конкурсларда, викториналарда безнең укучыларыбыз еш кына үзләрен җиңүчеләр итеп таныттылар һәм оештырылган төрле чараларда актив катнаштылар. Аларны башка балалардан аерым тәрбияләргә кирәк дигән фикер дөрес түгел. Безгә төрле милләтләр яшәгән җәмгыятьтә туарга һәм яшәргә насыйп булган. Балаларыбыз да төрле халыклар белән үзара тату яшәргә өйрәнеп үсәргә тиеш. Бу чара социализация дип атала.



Бәйгедә җиңүчегә бүләк тапшыру

Быелгы лагерьның эшчәнлеге һәм аның файдалы яклары турында бик күп сөйләп була. Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: биредә балалар Исламның гыйлем дәрьясы икәнлегенә төшенделәр. Дин тәртибендә яшәгәндә генә төрле уңышларга ирешеп, исәнсау һәм бәрәкәтле тормышта яшәп булуын аңладылар. Алар биредә туган телебезгә, милләтебезгә, мәдәниятебезгә карата олы ихтирам хисләре тупладылар.

Зур эшләр зур чыгымнар таләп итә. Танылган эшкуарларыбыз ярдәмендә без төрле ярышлар, конкурслар, викториналар һәм лагерьдагы бөтен балалар өчен матур Сабан туе да үткәрә алдык. Андагы гореф-гадәтләребезне, милли уеннарыбызны күрсәтү үзе бер табигый дәрес булды.

Болар барысы да иганәчеләребезнең актив ярдәме белән узды. Гомәр Батыршин, Фәхретдин Канюкаев, Габделбәр Савганов, Марат Ходов һәм Надир Әһлиуллин үз акчаларына төрле бүләкләр сатып алдылар.



Лагерь оештыруга зур ярдәм күрсәткән Дамир Ходов һәм мөфти Талип хәзрәт Яруллин

Үткән тәҗрибәгә таянып, киләчәк планнарыбызны тагын да камилләштереп, милләтебезне, динебезне үстерүдә яңа юлларын эзләячәкбез.

**Рәхимә Илдус кызы ХӘЕРОВА, «Яктылык» мәктәбе укытучысы, тәрбия эшләре буенча мәктәп директоры урынбасары:**

- Татар-башкорт балалары өчен Самара өлкәсенең Кинель-Черкассы районында оештырылган җәйге лагерьда быел миңа да укыту-тәрбия эшләре алып барырга насыйп булды. Минем белән бергә хезмәттәшләрем - «Яктылык» мәктәбе укытучылары Галия Тупасова һәм Гөлфия Глушкова да бу эштә актив катнаштылар. Балаларда туган телебезгә, милләтебезгә хөрмәт тәрбияләгәндә без үзебез дә әле күп нәрсәләргә төшендек. Әйтергә кирәк, безнең хәзерге мәктәпләрдәге укыту системасының эшчәнлеге әле дә диннән читтә тора. Әлбәттә, педагогика өлкәсендә бу - бер зур кимчелек һәм югалту. Быелгы лагерь эшчәнлегендә Ислам диненә кагылышлы мәгълүматлар, намаз уку тәртибе һәм дини кагыйдәләр буенча дәресләрне «Нур» мәдрәсәсе мөгаллиме Сәйфетдин хәзрәт Мөрсәлимов алып барды. Авылда әби-бабай тәрбиясе йогынтысында үсеп, дин турында бераз белсәм дә, мин бу лагерьда Исламның никадәр көчле тәрбия чарасы икәнлегенә тагын да ныграк инандым.

Биредәге укыту, тәрбия бирү, дәвалау һәм файдалы ял итү программалары тыгыз булса да, алар кызыклы, файдалы һәм бәрәкәтле иде. Бу оештыручыларның җентекләп, алдан уйлап эшләвенә бәйләнгән, әлбәттә.

Биредә минем ике балам да ял итеп дәваландылар һәм Ислам дине хакында төрле мәгълүматлар тупладылар. Шуңа күрә мин биредә педагог һәм әни кеше буларак та катнаштым. Монда балалар өчен тудырылган шартларга бик куандым һәм бу ялны оештыручыларга, бигрәк тә Радик Газизовка, Дамир Ходовка һәм Сәйфетдин хәзрәт Мөрсәлимовка, рәхмәтлемен.

Киләчәктә Ислам диненең тәрбия чараларын мәктәпләрдә, үз эшебездә дә куллана алсак, балаларыбыз намуслы, тәрбияле һәм уңай тормыш алып барырга сәләтле кешеләр булып җитлегерләр, Аллаһы теләсә.

**Сәйфетдин хәзрәт Мөрсәлимов, «Нур» мәдрәсәсе мөгаллиме:**

- Фән, техника һәм югары технологияләр торган саен киңрәк җәелеп, тормышыбызда зуррак урын ала барган чорда белемле булу, әлбәттә, аеруча мөһим мәсьәлә. Исламда гыйлем туплау гыйбадәттән дә өстен, дип санала. Ләкин шуны да әйтергә кирәк, тәрбиясе түбән булган кешенең белеменең үзкыйммәте дә түбән һәм аның файдасы аз була. Җәмгыятебездә тәрбиясезлек көчәя барганда кеше тәрбияләү проблемалары да арта бара. Исламда кеше тәрбияләү бөтен нечкәлекләре белән каралган. Динебез кешене әле үз-үзен тәрбияләргә дә өйрәтә. Төп тәрбияне мөселманнар гаиләдә һәм җәмгыятьтә алалар. Бу лагерьда да балаларга тәрбия бирүгә шундый киң мөмкинлекләр тудырылган.

Бер ук вакытта бала белем дә, тәрбия дә ала һәм төрле чирләрдән дәвалана. Балаларның һәм аларның укытучыларының, тәрбиячеләренең Ислам дине кануннары буенча һәм милли киемнәргә киенеп йөрүләре, аларның җыйнаклыгы, тыйнаклыгы — үзе бер шатлыклы күренеш. Киләчәктә бу тәҗрибә киң җәелеп, кеше тәрбиясенә әһәмият тагын да артса, яшь буын кешеләре акыллы, тәрбияле булып үсәрләр иде, Аллаһы теләсә.

Әйтергә кирәк, бу чараны оештыруда Диния нәзарәтенең яшьләр белән эш итү бүлеге җитәкчесе Радик Газизовның өлеше зурдан. Бихисап проблемаларны ул ничектер җиңел генә, бәрелепсугылмыйча, тынычлык белән хәл итә белә. Ул олылар, җитәкчеләр һәм шулай ук балалар белән дә уртак тел таба белә. Кыска гына вакытка каралган лагерь эшчәнлеген оештыруга озак, төпле әзерлек кирәк булды. Нәтиҗәләр куанычлы. Ата-аналар да, балалар да бик канәгать калдылар һәм шат күңел белән, якты истәлекләр туплап таралыштылар.

*Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.*